**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**ЗЕЛЕНАЯ РОЩА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**IV ЧАКЫРЫЛЫШ**

**УНСИГЕЗЕНЧЕ СЕССИЯ**

**КАРАР № 1**

Зеленая Роща авылы 2021ел, 25нче июнь

**Зеленая Роща авыл җирлеге Советының 2020нче елның 14 нче февралендә узган 64 нче сессиянең 1 нче карары -“Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә”гә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 ел, № 25-ФЗ Федераль законга, муниципаль хезмәт турында 25.06.2013 ел, №50-ТРЗ Татарстан Республикасы кодексына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы

**Зеленая Роща авыл җирлеге Советы**
**Карар:**

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә турында 2020 елның 14 февралендәге 64 номерлы Зеленая Роща авыл җирлеге Советы сессиясе карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 13 статьяда:

- 5 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:

5) җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»

2.Әлеге карар Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә һәм басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Зеленая Роща авыл җирлеге башлыгы Д. М. Хикмәтов**